**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУЛДЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

422980, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
пос. Юлдуз, ул. Центральная, д.1А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУЛДЫРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422980, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Йолдыз поселогы,
Центральная ур., 1А

тел. 884342 3-43-55, e-mail: Buld.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар

2020 елның 16 июле №8

Сайлау алды басма агитация материалларын
урнаштыру өчен махсус урыннар турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, белдерүләр стендларында һәм такталарында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Булдырь
авыл җирлеге башлыгы _____________ Н.Н.Воляков

Булдырь авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 16 июлендәге
8 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын адресы | Урнаштыру урыны исеме |
|---|---|---|
| 2761 | ТР,Чистай районы, Йолдыз авылы, Центральная тыкрыгы, 1 нче йорт | Мәдәният йорты |
| 2762 | ТР,Чистай районы, Булдырь авылы, Центральная ур., 51Д йорт | Мәдәният йорты |